ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 4** **14март 2024 ел**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Биектау торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 ноябрендәге 28 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләренә ярашлы рәвештә, татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 октябрендәге 17 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4.4 пунктчасы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 25 мартында 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Биектау авылы, Тынычлык урамы, 26 адресы буенча урнашкан бина янында, 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

2.1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2023 елның 24 октябрендәге 1 санлы гражданнар җыены карарын гамәлдән чыгарырга ризамы?

2.2. "Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Биектау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000,00 (бер мең) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә ризамы, һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлтүгә ризамы:

-Биектау торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зиратны коймалап алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, транспорт чыгымнары).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына граждannar җыенын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев